# БИИ ТАТАР ГҮЗӘЛЕ

Аягында чиккән читек,
Бии тыпыр-тыпырдап.
Толымнары китә тузып,
Бии ул кызып-кызып.

*Кушымта:*
Каршы чыгып биемичә
Йөрәгегез түзәрме?
Әйләнмәсен башларыгыз,
Бии татар гүзәле.

Идән тактасы чыдаса,
Нәфис аяклар чыдар.
Аңа каршы биергә, дип,
Әйдә, кайсыгыз чыгар?